Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы  муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
һәм тәрбия бирү учреждениясе“Шәдче балалар бакчасы”

# *Туган авылым*

**Төзеде:**
**Тәрбияче: Әхәтова Эльмира**
**Әмир кызы**

**2021 ел**

**Тема: “Минем туган авылым- Шәдче”.**

***(Мәктәпкә әзерлек төркемендә сөйләм үстерү дәресе)***

**Белем бирү өлкәсе**:”Танып белү үсеше”,”Иҗади-эстетик сәнгати үсеш”, ”Сөйләм үсеше”, ”Социаль-коомуникатив үсеш” .

**Максат:**

Балаларны туган авылыбызның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге , авылның һөнәр ияләре белән таныштыруны дәвам итү. Мөстәкыйль фикерләргә, картадан Республиканы, туган авылны күрсәтә һәм атый белергә, туган авылында булган үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү.Үстерешле диалог, сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.

**Бурычлар:**

1. Туган як турында балаларның белемнәрен системалаштыру, сорауларга тулы итеп җавап бирүләренә ирешү. Балаларның тыңлый белү, үз фикерләрен башкаларга җиткерә белү сәләтен үстерү.

2.Туган авылны зурлау, ана карата горурлык хисләре тәрбияләү.
3.Балаларнын логик фикерләү сәләтен, хәтерен, диалогик сөйләм күнекмәләрен,туган җиренә,тарихына кызыксыну уяту.
4.Авылыбызның нәрсә белән данлыклы булуы турындагы мәгълүматларын арттыру, белемнәрен киңәйтү.

**Сүзлек:** сәфәр, колач, кап сугу, әртил.

**Җиһазлау:**проектор, компьютер, слайдлар, Татарстан Республикасы картасы, аудиоязма, «Туган авыл » көе, плакат, төрле төстәге маркерлар, баш киеме – түбәтәй.

**Эшчәнлек барышы**
**Слайд**

**Тәрбияче**: Балалар карагыз әле бу слайдка. Сез бу слайдта нәрсәләр күрәсез? (Авыл өйләре, мәчет, мәктәп, урамнар, кешеләр) .
Балалар, минем дә сезгә бер күчтәнәчем бар.Нәрсә икән ул, ничек уйлыйсыз? Минем сезгә шигырьукып китәсем килә, игътибар белән тыңлагыз әле.

**Шигырь “Авылым”.**

Хәерле юл теләп озатып кала,
Сәфәр чыга калсам Шәдчедән.
Колач җәеп кабат каршы ала,
Тау башына менеп күренсәм.

Күл буенда үскән камышларың,
Башын ия йомшак җилләргә.
Бәхетемне күпме эзләсәм дә

Табалмамын чит-ят җирләрдә.

Урманыңда сайрар кошлар моңы,
Зәңгәр күктә тургай тавышы.
Әйтерсең лә яуда калганнарның,
Исәннәргә әйтер сагышы.

Чит җирләргә китеп озак йөрсәң,
Баса икән сагыш,уйлану.
Сагыну шул микән.туган якны
Төшләремдә күреп уяну.

- Нәрсә турында булды бу шигырь балалар? *(Туган авылыбыз турында).* Бу шигырьне безнең авылдашыбыз, җирле шагыйрь, журналист – Әмирхан абый Галәветдинов иҗат иткән. Ошадымы сезгә шигырь балалар?*(Әйе)*
- Димәк, авылыбызның исеме ничек? *( Шәдче авылы)* , (индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).
- Балалар авыл яки шәһәр – туган илнең бер өлеше ул. Туган ил,туган авыл әни шикелле газиз, якын. Әмирхан абый да шул турыда язган. Кая гына китсә дә, кеше туган ягын, туган авылын сагынып кайта.
- Әйдәгез ,безнен авылыбызны картадан табыйк әле , менә безнең туган авылыбыз - Шәдче. (картада балалар табып күрсәтә)
- Балалар,кайсыларыгыз үзенең урамын һәм йорт номерын белә? (б.җ.)
- Ә безнең районыбыз ничек атала? *( Мамадыш районы ),* (индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).
- Әйе, ә без нинди Республикада яшибез?(*Татарстан).* Әйдәгез әле, Татарстанны картадан табыйк. (картада балалар табып күрсәтә)
- Ә Татарстаннын башкаласы нинди шәһәр балалар? *(Казан).*
- Дөрес. Булдырдыгыз!
  **Тәрбияче:**Туган авыл, туган йорт һәркем өчен якын, кадерле. Алар турында кайгыртырга кирәк. Авылыбыз безнең бик матур.Анын иксез-чиксез кырларында игеннэр үсә.Тирә –яклар урманнар белән биләп алынган. Авылыбызнын уртасыннан «Шыя» исемле елга ага. Ә сез ничек уйлыйсыз, Шәдче исеме кайдан килеп чыкты икән?

**Туган авыл көе яңгырый**

**Слайд**

- Балалар, сезнен уйлап караганыгыз булдымы, элек туган авылыбыз нинди булды икән? (балалар җаваплары). Ә сезнен күрәсегез киләме? *(әйе*). Без бүген туган авылыбыз тарихына күз салырбыз.

- **Зөһрә :** Шәдче авылы – борынгы авыл.Минем ап-ак әбием Шәдчедә элек ике мәчет булган, авылыбызда һөнәрле, бик тырыш кешеләр яшәгән, - дип сөйли миңа.
- Әйе, бик дөрес Зөһрә.

**Презентация “ Шәдче тарихы”**

**Тәрбияче таныштыра.**

- Ә сез ничек уйлыйсыз, ул чорда Шәдчедә нинди һөнәр ияләре булды икән? (балалар җаваплары)

**Слайд “ Һөнәр ияләре”**

- Шәдче авылында киндер туку, икмәк пешерү, май язу заводы, игенчелек, терлекчелек һөнәр ияләре булган.
- Әйдәгез, алар белән якыннан танышып китәбез.

**Мини – музейны карап чыгу**

- Балалар,безнен әби- бабаларыбыз кич җыелып чигү чигәргә, кап сугарга, аулак өйләрдә төрле уеннар уйнарга яратканнар. Әйдәгез бездә сезнен белән “Түбәтәй” уенын уйнап алабыз.

**Физминутка Уен “Түбәтәй”**

- Балалар без бүген Шәдче тарихы белән таныштык. Әйтегез әле хәзерге вакытта безнен туган авылыбызда нинди үзгәрешләр булды? (балалар җаваплары).

**Презентация «Хәзерге Шәдче»**

- Әйе, авылыбызда бик күп төзелешләр булды, ул тагын да матурланды, ямьләнде.Авылыбыз урамнары асфальт, өйләребезгә су кергән, газ кергән. Менә мәдәният йортында да капиталь заманча төзекләндерү эше тәмамланып килә. Ул бик матур булачак. Без сезнең белән шундый заманча, матур авылда яшибез шулай бит.
- Сез, туган авылыбызны яратасызмы? **(***Әйе)*
- Ә аның тагын да матуррак булуын телисезме?(*Әйе)*
- Әйтегез әле, киләчәктә туган авылыбыз Шәдчедә нәрсәләр булыр дип уйлыйсыз? ( б.җ. )
- Әйе, безнен Шәдчедә парк төзелү көтелә, анда уен мәйданчыгы, спорт мәйданчыгы, фантаннар да булыр. Балалар, әйтегез әле паркларны кемнәр бизиләр? (*дизайнерлар).* Әйдәгез без сезнен белән дизайнерлар булабыз һәм булачак ял паркын бизәргә ярдәм итәбез.

**Плакатта маркер белән эш.**

- Карагыз әле балалар, нинди матур рәсемнәр килеп чыкты? Сез бик оста дизайнерлар булып чыктыгыз. Үскәч сездә парклар бизәрсез, авылыбызны матурлауда үз өлешегезне кертерсез дип уйлыйм.

**Рефлексия**

- Сезгә бүгенге шөгыль ошадымы?
- Без бүген нәрсә турында сөйләштек?
- Ә сез кайткач авылыбыз тарихы турында кемнәргә сөйләрсез?
- Сез бүген нинди яңалык белдегез?

**Мини - музей**

1) Слайд “Ипи пешерү”

Элек Шәдче авылының уртасында кул белән ипи пешерү бинасы, ә соңрак ипи пешерү заводы булган.Ул кайнар , тәмле, хуш исле икмәк белән үзебезнең авыл халкын гына түгел, тирә- як авылларга да хезмәт күрсәткән.

2) Слайд “ Май язу”.

Элек Шәдче авылында май заводы булган. Кешеләр үзләренең хуҗалыкларыннан сөт алып килеп май язганнар.

3) Слайд “ Тегүче”

Авылыбызда тегүче хезмәте зур урын алып торган.Элек тегү цехын “ Әртил” дип атаганнар. Анда күлмәкләр, чалбарлар, туннар теккәннәр.